Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы

# КАРАРЫ

2021 елның 30 апреле 53№

Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль районы җирле үзидарә
органы муниципаль хезмәткәрләре
реестрын алып бару тәртибе турында

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Әлки муниципаль районы Советының 2016 елның 17 ноябрендәге 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрларын алып бару эшчәнлеген камилләштерү максатларында Әлки муниципаль районы Советы Карар итте:

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми http:pravo.tatarstan.ru порталында һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Советының оештыру бүлеге начальнигына йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы: А. Ф. Никошин

Әлки район Советының
2021 елның 30 апрелендәге
53 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.Әлеге Нигезләмә 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Әлки муниципаль районы Советының 2016 елның 17 ноябрендәге 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибен һәм эчтәлеген билгели.

2.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре реестры Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре турында муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси эшләре, штат расписаниесе һәм җирле үзидарә органының башка исәп документлары нигезендә төзелгән мәгълүматларның җыелма исемлегеннән (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр) гыйбарәт.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре реестрына кертелгән муниципаль хезмәткәрләр турындагы белешмәләр конфиденциаль мәгълүмат булып торалар һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә якланырга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре реестры мәгълүматка рөхсәтсез керү, юк итү, модификацияләү, блоклау, күчерү, бирү, тарату, шулай ук башка законсыз гамәлләрдән саклауны тәэмин итеп «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба-мәгълүмат системасы) алып барыла.

## II. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару

5. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару (алга таба-Реестр) мәгълүмат системасында кадрлар эше алып бару өчен җаваплы хезмәткәрләр тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6. Реестрдагы мәгълүматта:

муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары;

муниципаль хезмәткәр униципаль хезмәт вазыйфасын биләп торучы җирле үзидарә органы исеме;

әлеге җирле үзидарә органы структур бүлекчәсе атамасы;

Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры нигезендә муниципаль хезмәткәр биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы исеме;

муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттәге кадрлар резервына кертү (кадрлар резервына кертү датасы, вазыйфа атамасы, кадрлар резервына кертү өчен нигез, кадрлар резервыннан төшереп калдыру өчен нигез).

7. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары үз эченә ала:

муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исемен (булганда);

туу датасын;

һөнәри белем (белем бирү оешмасының исеме, дипломның номеры һәм датасы, белгечлек һәм квалификация);

хәрби хезмәт үтү;

яңадан һөнәри әзерлек узу (белем бирү оешмасы исеме, уку тәмамлау датасы, программа исеме, йомгаклау документының төре һәм номеры);

квалификация күтәрү (белем бирү оешмасының исеме, уку тәмамлау датасы, программа исеме, йомгаклау документының төре һәм номеры);

гыйльми дәрәҗә (гыйльми дәрәҗә исеме, бирелү датасы);

гыйльми исем (гыйльми исемнең исеме, бирелү датасы);

көн, ай, елларда исәпләнгән гомуми хезмәт стажы;

көн, ай, елларда исәпләнгән муниципаль хезмәт стажы;

аттестация узу (аттестация үткәрү датасы, аттестация комиссиясе карары);

класс чины (класс чины, аны бирү турында актның датасы һәм номеры);

дәүләт бүләкләре һәм башка бүләкләр (бүләк төре, бүләкләү датасы);

конкурс нәтиҗәләре буенча граждан вазыйфасына билгеләнгән булса, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс узу;

хезмәт контракты (хезмәт контрактын төзү төре, датасы, аның гамәлдә булу вакыты, аңа үзгәрешләр кертү датасы).

Муниципаль хезмәткәрләрнең әлеге шәхси мәгълүмат исемлеге тулы исемлек булып тора һәм бары тик Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрына карата гына кулланыла.

8. Муниципаль хезмәткә керүче граждан турында белешмә җирле үзидарә органы җитәкчесенең билгеләү турындагы акты нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәннән соң ике эш көне эчендә реестрга кертелә.

9. Муниципаль хезмәткәрне шул ук җирле үзидарә органында башка вазыйфага билгеләгәндә аның муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнүе турында белешмә җирле үзидарә органы җитәкчесенең вазыйфага билгеләп кую турындагы акты нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәннән соң ике эш көне эчендә реестрга кертелә.

10. Муниципаль хезмәттән азат ителгән муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнне муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан төшереп калдырыла. Муниципаль хезмәткәр үлгән (һәлак булган) яисә муниципаль хезмәткәр хәбәрсез югалган дип танылган яисә законлы көченә кергән суд карары белән үлде дип игълан ителгән очракта, муниципаль хезмәткәр үлем (һәлак булу) көненнән яки суд карары законлы көченә кергән көннән соң килгән көндә муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан төшереп калдырыла.

Муниципаль хезмәткәр турында белешмәне реестрдан төшереп калдыру өчен шулай ук аның башка җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнүе нигез булып тора.

Күрсәтелгән нигезләр буенча муниципаль хезмәткәр турында белешмәләр реестрдан башка җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасына яки муниципаль хезмәт вазыйфасы булмаган вазыйфага билгеләнгәндә, эштән азат ителгән көннән соң килгән көнне, үлгәндә (һәлак булган) яки судның тиешле карары законлы көченә кергән көнне реестрдан төшереп калдырыла.

11. Реестрдагы тиешле үзгәреш турында белешмә мәгълүмати системага кертелә һәм департаментка җибәрелә.

12. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт узган һәм җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәр реестрыннан төшереп калдырылган муниципаль хезмәткәрләр турында белешмә закон нигезендә архивка тапшырыла.

13. Реестрны алып бару белән бәйле бәхәсләр законнар нигезендә карала.

## III. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып баруны тикшереп тору

14. Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып баруны контрольдә тотуны җирле үзидарә органы җитәкчесе тәэмин итә. онтроль шәхси эшләрнең булуын һәм муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси мәгълүматларын үз эченә алган мәгълүматларны җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр

реестрындагы мәгълүматлар белән чагыштыру рәвешендә торышын тикшереп гамәлгә ашырыла.

Мәгълүматларны тикшерү факты тиешле актта чагылыш таба.

15. Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрләр реестрын формалаштыру һәм алып бару буенча вазыйфа йөкләнгән муниципаль хезмәткәр конфиденциаль характердагы белешмәне тараткан өчен закон нигезендә җаваплы.

## IV. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәрләре реестрыннан белешмә бирү һәм реестрны саклау

16. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәрләре реестрыннан мәгълүмат Әлки муниципаль районы Башлыгы, Әлки муниципаль районы Башлыгы урынбасарына тапшырыла.

17. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәрләре реестры, аларга кертелгән үзгәрешләр, аларда булган мәгълүматка рөхсәтсез керү, юк итү, модификацияләү, блоклау, күчерү, бирү, тарату, шулай ук башка законсыз гамәлләрдән саклауны тәэмин итеп, мәгълүмат системасында саклана.